**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№6156**
**27.11.2019**

Җәмәгать сервитуты билгеләү турында

«Челтәрләр компаниясе» ачык акционерлык җәмгыятенең (ИНН 1655049111, ОГРН 1021602830930) юлламасын, күчемсез милек объекты турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан 2019 елның 20 октябрендәге 99/2019/2903555213 санлы өземтәне караганнан соң, Россия Федерациясе Җир кодексының 23 маддәсе, V.7 бүлеге, «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ санлы Федераль законның 3.6 маддәсе, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр челтәрләре хуҗалыгы объектларының сак зоналарын һәм мондый зона чикләрендә урнашкан җир участокларыннан файдалануның аерым шартларын билгеләү тәртибе турында» 2009 елның 24 февралендәге 160 нчы карары нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. «ЛЭП-110 кВ п/ст-1, Воздушная линия» электр челтәре хуҗалыгы объектын (алга таба – объект) урнаштыру максатында Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан, мәйданы 2056 кв.метр, кадастр номерлары 16:52:100101:154, 16:52:100102:49, 16:52:100102:15, 16:52:100102:27, 16:52:100102:36, 16:52:100301:202, 16:52:100102:39 булган җир участоклары өлешеннән файдалану өчен җәмәгать сервитуты билгеләргә.

2. Җәмәгать сервитутының чикләрен кушымтада каралганча расларга.

3. Җәмәгать сервитутының срогын 49 ел итеп билгеләргә.

4. Сервитутны гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә, әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән җир участогыннан рөхсәт ителгән файдалану нигезендә аннан файдалану мөмкин булмаган яки җитди кыенлашкан вакыт – 49 ел.

5. Җәмәгать сервитуты өчен түләү билгеләнми.

6. Объектка техник хезмәт күрсәтү буенча планлы (регламентланган) эшләр кварталга бер тапкыр башкарыла.

7. «Челтәрләр компаниясе» ачык акционерлык җәмгыятенә әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән җир участогын рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану өчен яраклы хәлгә китерергә, аны тәэмин итү өчен җәмәгать сервитуты билгеләнгән җир участогындагы эшчәнлек тәмамланганнан соң 3 айдан да соңга калмыйча объектны сүтеп алырга.

8. Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсенә әлеге карар кабул ителгән көннән башлап биш эш көне эчендә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

1) әлеге карарны (кушымтасыннан башка) «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгару һәм «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыру;

2) әлеге карарның күчермәләрен «Челтәрләр компаниясе» ААҖга һәм Татарстан Республикасы буенча Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография Федераль хезмәте Идарәсенең Яр Чаллы бүлегенә җибәрү.

9. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин